Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе

№5, 2015 ел январь

# Көмеш кыңгырау



## ТӨКЛЕ АЯГЫҢ БЕЛӘН, КӘҖӘ ЕЛЫ!

**2015 ел, Көнчыгыш календаре буенча, Кәҗә елы – үзгәрешләр елы булыр дип фаразлана. Кәҗәнең кирелеген,үҗәтлеген белгән хәлдә,аның холкы тәэсир итми калмас, янәсе. Кәҗә назга,имин,җитеш тормышка омтылса да, аның моңа ирешү ысулларында артык сайланып тормавы билгеле. 2015 елда кешеләрнең хезмәт шартларын җиңеләйтүгә яңа юллар ачылыр, бигрәк тә иҗади һөнәр ияләре өчен уңышлы ел булыр дип көтелә. Быел кәеф – сафа корып,акча туздырудан тыелып торырга,ут белшн шаярмаска, транспорт чаралары белән идарә иткәндә игътибарлы булырга, сәламәтлекне сакларга, спорт белән шөгыльләнергә киңәш ителә.**

**Кәҗә кебек үҗәт булу кирәк,**
**Максатыңа ирешү өчен.**
**Җитез,затлы, чиста бул, Кәҗәдәй,**
**Яман белән көрәшү өчен,**
**Яхшы белән берләшү өчен.**

**Тояк шакылдатып Кәҗә килә,**
**– Бир ! – димәсен.- Мә-ә - диеп торсын!**
**Сансыз – чутсыз кәҗә “бәтиләре”**
**Яңа елда исән – сау тусын!**
**Дөньялар бәхеткә тулсын!**

**2015 ел – Русиядә әдәбият, Татарстанда Парклар һәм Скверлар елы дип игълан ителде.**

**Бу санда:**

- **Хәрәкәттә бәрәкәт, 2 бит**
- **Бөек Җиңүнең 70 еллыгын каршылап..., 3 бит**
- **Математика һәм физика атналыгы, 4 бит**
- **Күңелле тәнәфес, 5 бит**
- **Котлаулар, 6 бит**

## Иң озын чирек башланды

Зарыгып көтеп алган кышкы каникуллар да тәмамланды. Чаңгы – чана шуып, әти - әниләребезгә йорт эшләрендә булышып, кызыклы китаплар укып, кинофильмнар карап, түгәрәкләргә йөреп, каникулның узып киткәнен сизми дә калдык. Мәктәбебезне һәм яраткан укытучыларыбызны сагынып,укырга килдек. Гыйнвар ае да чараларга бай булды,аларның кайберләренә тукталып үтү урынлы булыр. 14 гыйнвар көнне ата – аналар җыелышы үткәрелде, анда мәгариф бүлеге психологы Г.Р.Зиннатова катнашып, суицид,аңа китергән сәбәпләр, профилактика чаралары хакында сөйләде. Укытучы Т.М.Асманованың “ Басма көне” уңаеннан үткәргән информацион иртәсе дә файдалы һәм кызыклы булды. Мәктәбебез җитәкчеләре район мәгариф бүлегендә уздырылган гыйнвар киңәшмәсендә катнашып, төп дәүләт имтиханына әзерлек,укытуның сыйфаты,фән олимпиадалары нәтиҗәләре турында чыгыш ясадылар. Якташ галимнәребезнең иҗатларына багышланган “ Тамырлары шушында, бәрәкәтле туфракта” дип исемләнгән районкүләм чарада Г.М.Закирова якташыбыз Р.Үтәбай – Кәрими турында чыгыш ясады. Ю.Кибәхуҗа мәктәбендә “Ел сыйныф җитәкчесе - 2015” конкурсының район туры булып үтте. Конкурста мәктәбебезнең V сыйныф җитәкчесе Л.И.Хәбибуллина катнашты һәм “Педагогик осталык” номинациясендә җиңүче дип табылды. Котлыйбыз! Халыкара дистанцион татар теле олимпиаласында катнашып, II сыйныф укучысы Рәхмәтуллина Д. Җиңүче Дипломы белән бүләкләнде, ә укытучысы Р.Х.Газизова Рәхмәт хатына ия булды. Тәбрик итәбез!

# Хәрәкәттә - бәрәкәт


**Гимнастика, физик күнегүләр,җәяү йөрү эшләү сәләтен, саулыгын,тулы куәтле шат күңелле тормышын сакларга теләгән һәркемнең көндәлек тормышында урын алырга тиеш.**

**ГИППОКРАТ**



*Флүзә Гайсиновна Әскарова, география һәм биология укытучысы:*

-Кышкы спорт төрләреннән чаңгы аеруча күңелемә хуш килә.Чаңгыда шуарга мәктәп елларыннан бирле яратам.Арча педагогия училищесында укыганда чаңгы ярышларында катнашып, призлы урыннарны күп яуладым. Көн саен чаңгыда йөреп кайтмасам, ниндидер мөһим эшем эшләнеп бетмәгән кебек тоела. Бәрәңге бакчабызга чаңгы юлы салдым, Чаңгыларым да яңа, сезон башланыр алдыннан,быел гына Арчадан сатып алдым. Спортка буыннар каткач,аяклар хәрәкәтләнми башлагач түгел, яшьтән килергә кирәк дип саныйм! Иренмәскә! Вакыт бар ул, җитешеп булмый дигәнебез сылтау гына! Үзеңдә көч табарга гына кирәк!



***Ришат Гомәрович Даутов,*** *физик культура укытучысы:*

-Укучыларыбыз физик культура дәресләрендә чаңгыларга бастылар.Мәктәп нең спорт мәйданчыгында чаңгы юллары салынды.Укучылар чаңгыда йөрү буенча нормативлар тапшырырга әзерләнәләр. Балаларга чаңгыда үтә торган физкультура дәресләре бик ошый.

## Халык әйтсә, хак әйтә

- **Тере тәннең ямаулыгы үз өстендә**
- **Нечкә билле, эшкә җилле**
- **Хәрәкәтсезнең сөяге тутыга**
- **Хәрәкәт – картлыкка каршы көрәштә иң эффектлы ысул**

## Спорт дөньясы хәбәрләре

***Республика буенча:***

* Боливия, Чили һәм Аргентина буйлап узган,13 этаптан торган “Дакар - 2015” ралли – марафоны тәгәлләнде. “КАМАЗ - мастер” узышчылары мактау баскычында башка бер генә команда вәкилләренә дә урын калдырмады. Йөк машиналары арасында гомуми нәтиҗәләр буенча А.Мәрдиев беренче,Э.Николаев икенче, А.Каргинов өченче урынга лаек булды.

* Кышкы универсиада. 24 гыйнварда Словакиядә XXVII кышкы Универсиада старт алды. Анда Татарстан данын дүрт спортчы яклый. Универсиаданың беренче көнендә үк Татарстан чаңгычысы Андрей Ларьков Русия командасына беренче “алтын ”бүләк итте.

***Район буенча:***

**Баландыш төп мәктәбе базасында М.Сафин призына көрәш ярышы үткәрелде.

**Теләче чаңгы базасында район беренчелеге булып узды.

***Артспорт буенча үткәрелгән ярышта мәктәбебез укучылары Гыйльметдинова Л. өченче ,Шангараев Р. икенче урынга лаек булдылар.

**КОТЛЫЙБЫЗ!!!**

## Физкультура белән шөгыльләнүчегә

**# Ятактан кисәк сикереп тору умыртка , буыннар өчен зыянлы. Йокыдан уянуга елмаеп, үзеңә хәерле көн теләп, хәрәкәтне урында яткан килеш бераз киерелүдән, кул – аякларны сузып, 1-2 минутлык гади генә күнегүләр эшләп алудан башлау яхшы.**

**# Спорт белән йокыга кадәр 2 – 3 сәгать алдан шөгыльләнү тиеш, ә йоклар алдыннан нерв системасын тынычсызлау дөрес эш түгел, саф һавада булу да җитә.**

**# Физик зарядканы бүлмәдә эшләргә туры килсә., гигиена таләпләренең үтәлүе кирәк,бүлмә тузанлы булмасын,форточка ачык торсын,әмма үтәли җил йөрмәсен.**

# Бөек Җиңүнең 70 еллыгын каршылап...



**Бөек Ватан сугышы: саннар һәм фактлар**

Математика укытучысы Галимҗанова Г.Ә. мәктәбебездә "Бөек Ватан сугышы: саннар һәм фактлар" исемле кече фәнни - гамәли конференция үткәрде. Чарада үзенең тикшеренү эше белән 9 нчы сыйныф укучысы Даутова Дилбәр чыгыш ясады. Ул катнашучыларны презентация ярдәмендә Бөек Ватан сугышы нәтиҗәләре буенча чыгарылган саннар һәм фактлар белән таныштырды.



**Җиңүнең 70 еллыгына**

"Тегү дөньясы" түгәрәгендә илебезнең Бөек Ватан сугышында Җиңүенең 70 еллыгына ныклы әзерлек бара. Өстәмә белем бирү педагогы Шаипова Р.И. хәрби кием тарихын өйрәнеп, түгәрәккә йөрүче укучылар белән хәрби костюмнар тегә башладылар.Афәрин, кызлар!



9 нчы сыйныф укучылары Әскаров Данис, Шангараев Рушан ,7 нче сыйныф укучысы Серапионов Арслан, 6 нчы сыйныф укучысы Рахматуллина Энҗе тарих укытучысы Рахматуллина А.Ә җитәкчелегендә Казаклар авылында урнашкан, илебез азатлыгы өчен Бөек Ватан сугышында вафат булган авылдашларыбыз хөрмәтенә куелган һәйкәл янын кардан чистарттылар.



**Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган математик иртә.** Мәктәбебезнең югары категорияле математика укытучысы Әхмәтҗанова Найлә Нуретдиновна 4-5 сыйныф укучылары белән балаларда патриотизм хисләре тәрбияләүгә юнәлтелгән "Бөек Җиңүгә- 70 ел" исемле иртә үткәрде. Укучылар өчен тәкъдим ителгән мисал һәм мәсьәләләрнең җавапларындагы һәр сан сугыш вакыйгалары турында сөйли иде. Укучылар чарага ныклап әзерләнгәннәр, бик актив булдылар.Иртә “Җиңү көне” җыры белән тәмамланды.Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый!



**Каләмне корал итеп**

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хужина Н.Ю. мәктәп күләмендә "Каләмне корал итеп" дип исемләнгән балалар иртәсе үткәрде. Бу тәрбияви чара Бөек Ватан сугышында катнашкан татар шагыйрьләренә, язучыларына багышланды. Бөек Ватан сугышында 104 язучы катнашкан, 31 е кире әйләнеп кайтмаган.Сугышта катнашкан язучылар арасында безнең якташларыбыз да бар. Алар: Мәхмүт Максуд һәм Габдулла Галиев. Нәкыя Юнысовна презентация ярдәмендә әдәбият әһелләренең Җиңүне якынайтуга керткән өлешләре белән таныштырды.

**Һәйкәл булып баса җиңүчеләр,**
**Һәйкәл булып баса батырлар.**
**Ә батырлар ике тапкыр үлми**
**Җирдә алар мәңге балкырлар.**
**70 ел инде һәр көн саен**
**Кайтмый калганнарны көтәбез,**
**Авыл уртасына һәйкәлләргә**
**Башыбызны иеп киләбез...**

# Математика һәм физика атналыгы

**МАТЕМАТИКА ҺӘМ ФИЗИКА АТНАЛЫГЫ  ПРОГРАММАСЫ:**

**26.01.** – Атналыкны ачу. “Бөек Җиңүгә - 70 ел” һәм “2015 ел –Татарстан Республикасында Физика елы” уңаеннан ***“Интеллектуаль турнир”*** *(1- 9  кл)* “Фантазия” темасына иҗади эшләр, “Иң пөхтә математика” һәм “Иң пөхтә физика дәфтәре ” конкурсларын игълан итү.

**27.01.** – ***“Математик аукцион”*** (6 – 7 сыйныф укучылары  )

**28.01.**- “Бөек Җиңүгә - 70 ел” темасына ***математик  иртә*** *( 4 – 5 сыйныф )*

**29.01.** – “Физика  безнең әйләнә - тирәбездә” темасына ***физик турнир*** *(7 – 8 сыйныф укучылары)*

**30.01.** – “Бөек Ватан сугышы: саннар һәм фактлар”  темасына ***фәнни – эзләну эшен презентацияләу***
*(5 – 9 сыйныф укучылары)*

**31.01.**- Атналыкны йомгаклау.

Атналыкны мавыктыргыч, файдалы, истә калырлык итеп үткәргәннәре өчен математика укытучыларыбыз **Найлә Нуретдиновнага, Гөлнур Әхмәтзәкиевнага,** физика укытучыбыз  **Хәдичә Нургалиевнага** ихлас рәхмәтләребезне  җиткерәбез!

***“Интеллектуаль турнир”*** **җиңүчеләре:**
**I урын** -   Гыйльметдинова Л. ,VIII кл.
Даутова Д., IX кл.
**II урын** – Даутова Г., VI кл.
Мөхәммәтҗанов Ф., VII кл.
**III урын** – Серапионов А., VII кл.

***“Математик аукцион”нәтиҗәсе:***
“Минус” командасы (VII кл. укучылары)- 429 балл
“Плюс” командасы (VI кл. укучылары)- 392 балл
Җиңүче: VII кл. укучыларының  “Минус” командасы

***“Физика безнең әйләнә - тирәбездә”*** **физик турниры җиңүчеләре:**
**I урын** -   Гыйльметдинова Л. ,VIII кл.
**II урын** –  Ибраһимов Р., VIII кл.
**III урын** – Серапионов А., VII кл.
Шәйхетдинов Ф., VII кл.

Атналыкта **иң актив** катнашкан, **Грамота** белән бүләкләнүче укучылар:

Шәяхмәтова С. , V кл.
Әхмәтҗанова А. ,V кл
Әскарова А., VI кл.
Серапионов А., VII кл.
Гыйльметдинова Л. ,VIII кл.
Даутова Д., IX кл.

**ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ ТӘБРИК ИТӘБЕЗ!**

## Атналыкның күңелле мизгелләре...








# Күңелле тәнәфес

## КЫШНЫ ЯРАТАСЫЗМЫ?

### *ТЕСТ*

**1. Бик салкын булса, өйдә утырасызмы?**
**2. Кыш көне сәяхәткә чыгарга яратасызмы?**
**3. Чаңгыда яисә тимераякта шуа беләсезме?**
**4. Кар яуганны яратасызмы?**
**5. Кыш көне зарядка ясарга ихтыяр көчегез җитәме?**
**6. Кыш сурәтен ясарга яратасызмы?**
**7. Кыш көне гел урамда гына йөрергә кирәк дип уйламыйсызмы?**
**8. Кышын җәй көненә караганда озаграк йоклыйсызмы?**
**9. Кар әвәләп, төрле фигуралар ясарга, кар атышып уйнарга яратасызмы?**
**10. Кышкы ял көннәрен көнозын китап укып, телевизор карап, компьютерда уйнап, өйдә үткәрәсезме?**

**Әгәр 2,3,4,5 сорауларына “әйе” дип, 1,7,8,9,10 сорауларына “юк” дип җавап бирсәгез, һәрберсенә 1әр очко алдым дип исәпләгез.**

**<u>10-7 очко</u> – сез, чынлап торып, “кар кешесе”. 365 көн буена кыш булса да, шатлана беләсез.**

**<u>7-4 очко</u> –сез теләсә кайсы ел фасылында да узегезне әйбәт хис итәсез.**

**<u>3-1 очко</u> –сез кышны бик яратып бетермисез.**

## *ТИЗ ГЕНӘ ӘЙТЕП БИР!*

*(эрудитлар өчен)*

***1. Җирнең радиусы күпме?***
***2. Дециметр  безгә нәрсәгә кирәк?***
***3. Ни өчен янгын щитындагы чиләк гадәти булмаган конус формасында?***
***4. Әдәбият  өлкәсендә  Нобель премиясенә лаек булучылар кемнәр?***
***5. 1 пот купмегә тигез?***
***6. Австралиянең башкаласы?***
***7. Наташа Ростова  кемгә кияүгә чыга:Андрей Болконскийгамы, әллә Пьер Безуковкамы?***
***8. “Ак квадрат” белән кемнәрне бүләклиләр?***

**Шакмаклар эченнән 18 кош исемен табыгыз**

## КӨЛДЕРГЕЧЛӘР

- Мияу!
- Һау-һау!
- Син нәрсә, котырдыңмы әллә?
- Юк, чит тел өйрәнәм.

***********************************

Укытучы:
- Алмаз, ике алмашлык әйт әле.
- Кем, минме?
- Дөрес, “5”ле куям сиңа.

***********************************

Бер укучы имтихан биреп чыга.
Иптәшләре дулкынланып:
- Ничек, бирдеңме? –дип сорыйлар.
- Бирдем, ахрысы.
- Укытучы ни сорады соң?
- Кем белә инде аны, инглизчә сорый бит.

***********************************

Беркөнне Алмаз мәктәпкә ап-ак булып килеп керә.
- Авырып киттеңме әллә? –ди укытучысы.
- Юк, кичә әнием мине ваннада юындырды.

***********************************

- Сукыр тычкан көн саен үз авырлыгы кадәр азык ашый.

Алмаз:
- Ул узенең ничә килограмм икәнен каян белә соң?

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | Ә | Ш | С | Б | Г | Ы | Ш | С | У |
| Е | Р | Ә | О | А | Й | Р | Ә | Р | Е |
| Ч | У | К | К | А | Ч | Ү | К | Ә | Й |
| Б | Р | Ы | Б | Ы | Л | Ш | Ә | Ү | Л |
| О | Җ | Ы | Р | Ы | Б | Н | Ә | Г | Е |
| К | Е | Н | Ә | Л | К | А | Р | А | К |
| Б | Ө | Р | Р | И | К | А | Р | Ч | О |
| Т | Е | К | Т | Ә | В | И | С | Ы | Ш |
| К | К | А | Р | Г | А | Ч | Е | Г | А |
| Ү | К | Е | Ә | Т | Ә | Ч | Л | Ә | Н |

# Котлыйбыз!



**Хөрмәтле укытучыларыбыз Наилә Дәүләтҗановна,Ильмира Мансуровна! Сезне гомер бәйрәмнәрегез белән тәбрик итәбез! Сезгә озын гомер, нык сәламәтлек телибез!**

***Үлчәнмәгән Сездә рухи ныклык***
***Ташып тора җанда егәрлек.***
***Бирсен Аллаһ Сезгә ныклы саулык***
***Гомер тауларына менәрлек.***
***Алга әйдәп балкый, дәшә һаман***
***Өмет кояшының нурлары.***
***Сәламәтлек, яхшы кәеф белән***
***Каршылагыз килер елларны!***

**Күңел кояшыгызны сүндерми, тирә-юньдәгеләргә яшәү көче биреп, әле озак еллар дөньяга якты нур өләшеп яшәргә язсын. Һәр ирешкән уңышыгызның нәтиҗәсен күреп куанырга насыйп булсын. Укучыларыгызның ихтирамын, якыннарыгызның куңел җылысын тоеп яшәгез!**

Укучыларыбыз **Даутова Гөлшатның, Саидов Мирзомидинның,Миннебаев Мөнәвирнең** гыйнвар аенда туган көннәре. Сезне туган көннәрегез белән котлыйбыз! Укуыгызда уңышлар,ак бәхетләр телибез.




Туган көннәрегез котлы булсын,
Юлыгызга гөлләр сибелсен.
Киләчәкнең туар таңы сезгә,
Мәңге сүнмәс бәхет китерсен.

**********************************

Сезнең йөргән юлыгызда ,
Очрамасын киртәләр.
Гел шатлыклар, гел бәхетләр,
Алып килсен иртәләр.

Газетаны гамәлгә куючы: ТР Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе администрациясе
Редколлегия әгъзалары:
**VI сыйныф** укучылары
**Баш мөхәррир:**
**VI сыйныф җитәкчесе**
**Х.Н.Нигъмәтҗанова**



Безнең адрес:
422080, Теләче районы,
Кече Кибәхуҗа авылы,
Кече урам ,10 нчы йорт.
Белешмәләр өчен телефон:
56 – 2 – 40
e-mail: mkibiakozi40@mail.ru